**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 22 декабрендәге 4612 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4723 номерлы «“Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасы турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 31 декабрендәге 4723 номерлы «“Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү” максатчан программасы турында»гы карарына (аңа 2017 елның 31 гыйнварындагы 182 номерлы, 2018 елның 25 апрелендәге 1612 номерлы, 2018 елның 13 ноябрендәге 5808 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 2171 номерлы, 2019 елның 7 августындагы 2833 номерлы, 2019 елның 4 октябрендәге 3567 номерлы, 2019 елның 19 декабрендәге 4553 номерлы, 2020 елның 5 июнендәге 1603 номерлы, 2021 елның 18 июнендәге 1509 номерлы, 2021 елның 8 декабрендәге 3255 номерлы, 2022 елның 18 маендагы 1452 номерлы, 2024 елның 20 февралендәге 563 номерлы, 2025 елның 22 июлендәге 2335 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне иәпкә алып) «Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасын гамәлгә ашыру кысаларында яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен социаль түләүләр бирү кагыйдәләренең («Казан шәһәрендә яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» максатчан программасына 1 номерлы кушымта) 14 нче пунктын түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасы белән тулыландырып үзгәреш кертергә:

«з) махсус хәрби операциядә катнашкан иренең (хатынының) үлеме турында таныклык күчермәсен (булган очракта)».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми

мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**